КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 сентябрь г.Казань № 889

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 25 сентябрь 866 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы
карары белән расланды

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив чыгымнар, бер елга бер берәмлеккә сум | Бер елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыруга, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле архив белешмә кәгазьләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, мәгълүмат хатларын бирү | 1 525,63 | 18 000 | үтәлгән соратулар саны, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан (күчермәләреннән), аларның белешмә һәм эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 890,64 | 10 000 | уку залында булу саны, берәмлек |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы
карары белән расланды

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш башкару исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 14 843 973 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм аларны исәпкә алу | 30 430 144 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә һәм эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 7 421 986 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 2 968 795 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәне документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 4 453 192 |
| 6. | Архив документларының белешмә һәм эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 5 195 390 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 7 421 986 |

_______________________________